| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НОВОИШТЕРЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯҢА ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2022 елның 02 феврале № 3

«Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 06 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Яңа Иштирәк авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 11 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

143 пунктның 1 пунктчасында «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлектән килеп чыккан продукция» сүзләренә алыштырырга.
(2023 елның 1 мартыннан үз көченә керә).

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылы, Үзәк урам, 7 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Иштирәк авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Г.Р.Мәүлетова